КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 октябрь г.Казань № 1244

«Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә Ш.К.Еникеев исемен бирү турында

Сукыр язучы, җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче Еникеев Шәриф Кәлимулла улы истәлеген мәңгеләштерү максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә Ш.К.Еникеев исемен бирергә һәм алга таба аны «Ш.К.Еникеев исемендәге сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе» дип атарга дигән тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә «Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе Уставына тиешле үзгәрешләр кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин